**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2020 елның 3 августыннан** **№ 157**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 19 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 8 августыннан 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2013 елның 25 маеннан 62а номерлы Песәй авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы Боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 маеннан 62а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Песәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милектән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;
- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбия бирүнең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы Карары проектын карап тикшерү буенча гавами тыңлаулар 2020 елның 4 сентяберендә 16 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Песәй авыл җирлеге, Песәй авылы , Мәктәп тыкрыгы, 3 нче йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге мәдәният йорты бинасында.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең "Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы карар проекты белән танышу чорында югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен оештырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәләр: Татарстан Республикасы, Песәй авыл җирлеге, Песәй авылы, Үзәк урамы, 4 нче йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында бастырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советы Рәисе В. И. Мөхәммәтгалиев

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советының
2020 елның «3»августагы
157 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Рәис: Мөхәммәтгалиев Вильдан Ильсур улы - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге Башлыгы;
2. Рәис урынбасары: Мөхәммәтгалиев Ильшат Гарифҗан улы – Песәй авыл җирлеге Советы Рәисе урынбасары, Песәй авыл җирлеге Советы Депутаты;
3. Секретарь: Ситдикова Гөлназ Ильдус кызы – Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
4. Комиссия әгъзасы: Тимербаев Наил Шакирҗан улы – Песәй авыл җирлеге Советы Депутаты;
5. Комиссия әгъзасы: Җиһангәрәев Ильнар Ринат улы – Песәй авыл җирлеге Советы Депутаты;
6. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы Инвестицион һәм инфраструктур үсеш идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.